ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.12.2020 № 1256

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2014-2020 елларга Алабуга муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 8 маендагы 512 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2014 елның 9 июлендәге 765 карары нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2014-2020 елларга Алабуга муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2014 елның 8 маендагы 512 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемендә «2014-2020 еллар» сүзләрен «2014-2023 еллар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарга теркәлгән «2014-2023 елларга Алабуга муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасын яңа редакциядә расларга.

3. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «2014-2023 елларга Алабуга муниципаль районында Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыру өчен бюджет ассигнованиеләрен күздә тотуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Ягудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов